ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

18 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елнын 06 октябрендәгы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Яхшы-Каран авылы территориясендә теркәлгән инвалидлардан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр) һәм көндезге уку формасы буенча укучы, хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәтләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Яхшы-Каран т. п. Идрисов хэм Мифтахов урам юлларына вак таш җәю;

2) Яхшы – Каран т.п. урамнарны яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);

3) Өлкәннәр көненә, инвалидлар көненә бүләкләр алу;

4) "Сабантуй" һәм «Яңа ел " бәйрәмнәренә призлар һәм бүләкләр алу;

5) Яхшы- Каран т.п. мэдэният йорты түбәсен ябу;

6) Яхша-Каран т.п. җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo. tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Ф.Вафин